# КАРАР

**“16” ноябрь 2021 ел** **№ 10**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 16 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 327,5 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 655 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдеру белән килешәсезме:

1. Юл-урам челтәренә вак грунтташ урнаштыру:
Лесная ур., 9 нчы йорттан башлап;
2.Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту
3.МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны өлешчә финанслау (Ротор чапкычы, фронталь төягеч).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 27 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 14 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 14 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Гарталовка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 327,5 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 655 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Юл-урам челтәренә вак грунтташ урнаштыру:

Лесная ур., 9 нчы йорттан башлап;

2.Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

3.МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны өлешчә финанслау (Ротор чапкычы, фронталь төягеч).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Гарталовка авылы, Урман урамы, 5 нче йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков